СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2022 г.Зеленодольск № 159

2022 елда «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мактаулы гражданнарына» түләүләр күләмен билгеләү турында

2022 елда Зеленодольск шәһәренең 90 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. 2022 елга «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мактаулы гражданы» исеменә лаек булган затларга түбәндәге түләүләр күләмен билгеләргә:

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мактаулы гражданы» исемен биргәндә бер мәртәбә акчалата бүләкләү - 30000 (утыз мең) сум;
- шәһәр көненә акчалата түләү - 5000 (биш мең) сум.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2007 елның 30 июлендәге 210 нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мактаулы гражданы» исеме турындагы нигезләмәнең 1.4 пунктының һәм 3.2 пунктындагы бишенче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**